| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 сентябрь г.Казань № 839

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы буенча төп параметрлар, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турында

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы буенча төп параметрлар, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турындагы докладны тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы буенча төп параметрларны хупларга.
2. 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.
3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2020 елның 30 сентябренә кадәр «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән берьюлы кертелә торган

документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына 2020 елның 30 сентябренә кадәр «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга билгеләнгән тәртиптә кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин